**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Олы Яңасала авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

6 нчы декабрь 2022 ел № 2

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 нче елның 6 нчы декабрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясе Олы Яңасала авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Яңасала авыл җирлеге территориясендә яшәүче, җирлек территориясендә тавыш бирергә хокукы булган, яшәү урыны буенча турыдан-туры теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 1000,00 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:
- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш белән чокырларны ямау, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чабу(килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, чапкыч сатып алу);
-янгын сүндерү машинасын карап тоту ( ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- кышкы чорда территорияләрне кардан чистарту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү); -
зират территориясен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);
- сусаклагычны (су савытын) чистарту, юу (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 192 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 101 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 101 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге составына керүче Олы Яңасала авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

«2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясе Олы Яңасала авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясендә яшәүче, җирлек территориясендә тавыш бирергә хокукы булган, яшәү урыны буенча турыдан-туры теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 1000,00 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш белән чокырларны ямау, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чабу(килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, чапкыч сатып алу);
-янгын сүндерү машинасын карап тоту ( ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- кышкы чорда территорияләрне кардан чистарту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- зират территориясен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);
- сусаклагычны (су савытын) чистарту, юу (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк урам, 1;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Шәпкә авылы, Клуб урамы,14, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге
башлыгы: И.Х.Шиһабеев